Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге составына керүче Мельничный Починок авыл җирлегендә гражданнар җыены **КАРАРЫ**

30 ноябрь 2021 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге составына керүче Мельничный Починок авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Мельничный Починок , Наратлы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан гайре) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- авыл җирлеге чигендәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту өчен ;

- Уракчы авылы Яр буе урамы юлларын ремонтлау, Совет урамы чокырларын тигезләү , Мельничный Починок авылы Давыдов урамы юлларын ремонтлау , Елгаарьягы һәм Киров урамы чокырларын тигезләү , Наратлы авылы Карбышева урамы юлларын ремонтлау өчен;

-трактор өчен өстәмә җиһазлар сатып алу;

- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү өчен;

- авыл җирлеге чигендәге су белән тәэмин итү җайланмаларын тәртиптә тоту өчен (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- авыл җирлеге чикләрендә урамнарны яктырту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

-Мельничный Починок авылындагы чишмәне сууткәргечен өлешчә алыштырып төзекләндерү өчен.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гәрәев Ф.М.

Уракчы авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Ф.М